ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НИЖНЕКАМСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

пр. Строителей, д.12, г. Нижнекамск, 423570

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Төзүчеләр пр., 12 нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

01 10 2021 г. № 850

Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 7 декабрендәге 1031 номерлы карары белән расланган «Балаларны мәктәпкәчә белем бирүнең төп гомуми белем бирү программасын (балалар бакчалары) тормышка ашыручы мәгариф учреждениеләренә (оешмаларга) исәпкә кую һәм кабул итү» муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләре нигезендә, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының «Түбән Кама муниципаль районында муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында» 2010 елның 18 ноябрендәге 1491 номерлы карарына таянып, Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 7 декабрендәге 1031 номерлы карары белән расланган «Балаларны мәктәпкәчә белем бирүнең төп гомуми белем бирү программасын (балалар бакчалары) тормышка ашыручы мәгариф учреждениеләренә (оешмаларга) исәпкә кую һәм кабул итү» муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.4. пунктының егерме өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Бала аның бертуган һәм төрле әти яки әнидән туган абыйсы һәм (яки) апасы укый торган мәктәпкәчә белем бирүнең төп гомуми белем бирү программалары буенча муниципаль муниципаль белем бирү оешмасына укырга өстенлекле кабул итү хокукына ия.»;

3.4.5 пунктының сигезенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Ата-ана (законлы вәкил) гаризасы буенча баланы буш урыннар булган башка мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләренә вакытлыча кабул итү рөхсәт ителә.

Баланы тиешенчә комплектланмаган мәктәпкәчә белем бирү учреждениесенә вакытлыча кабул итү чоры әлеге регламентта каралган муниципаль хезмәт күрсәтүнең гомуми вакытына керми. Мәктәпкәчә белем бирү учреждениесендә беренчел гариза буенча чират саклана.

Вакытлыча кабул итү турында гариза Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының «Мәктәпкәчә белем бирү үзәге» муниципаль бюджет учреждениесенең комплектлаштыру бүлегенә бирелә.».

2. Җәмәгатьчелек һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлегенә әлеге карарны Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының рәсми сайтында басма матбугатта урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары – Мәгариф идарәсе җитәкчесе Р.М. Гыйниятуллинга йөкләргә.

Җитәкче А.Г. Сәйфетдинов